**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки**
**муниципаль районы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56
тел: 8 (84346) 2-17-60

Адрес: 422870, РТ, с.Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56
факс: 8 (84346) 2-17-60

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2021 елның 15 декабре 525№

Әлки муниципаль районы мәдәният учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә (башкарыла) һәм Татарстан Республикасында 2022 елга бюджетара мөнәсәбәтләр формалашканда исәпкә алына торган муниципаль хезмәтләргә (эшләргә) норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 5 сентябрендәге «Муниципаль учреждениеләр тарафыннан башкарыла торган һәм Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлеген раслау турында» 638 номерлы һәм 2021 елның 22 сентябрендәге «2022 елга Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда файдаланыла торган Татарстан Республикасында музейлар, китапханәләр, мәдәни-ял итү тибындагы учреждениеләр тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару кыйммәте нормативларын раслау турында» 893 номерлы карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елга Әлки муниципаль районы мәдәният учреждениеләре тарафыннан 2022 елга муниципаль хезмәт күрсәтүләргә кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнарны 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми http:pravo.tatarstan.ru порталында һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче: И. В. Юсупов

1 нче кушымта

**2022 елга Әлки муниципаль районы мәдәният учреждениеләре күрсәтә торган муниципаль хезмәтләргә НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| т/б № | Учреждение исеме | Хезмәт исеме | Норматив чыгымнар, сум | Елга хезмәт күрсәтү күләме | Үлчәү берәмлеге |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Музейлар | музей предметларын, музей коллекцияләрен халык алдында күрсәтү | 437,20 | 14733 | берәмлек |
| 2 | Китапханәләр | китапханәдән файдаланучыларга китапханә, библиографик һәм мәгълүмати хезмәт күрсәтү | 66,19 | 295324 | берәмлек |
| 3 | Клуб тибындагы учреждениеләр | кинофильмнар күрсәтү, клуб оешмалары һәм үзешчән халык иҗаты оешмалары эшчәнлеген оештыру | 334,63 | 168875 | берәмлек |